# Бәшарова Фиразия Рамазан кызы



Бәшарова Фиразия Рамазан кызы 1955 елның 19 гыйнварендә Минзәлә районы Яңа Иркәнәш авылында, колхозчы гаиләсендә дөньяга килгән. Үз авылларында башлангыч сыйныфны "4","5"ле билгеләренә тәмамлап, Иске Иркәнәш сигезъеллык мәктәбенә 5 класска укырга керә. 1970 елда аны тәмамлап, Иске Матвеевка урта мәктәбедә 9 рус классында укый башлый. 1972 елда Алабуга дәүләт педагогия институтына укырга керә. 1977елны институт тәмамлаган белгечне Мөслим районы Үрәзмәт авылына математика укытырга җибәрәләр. Анда 5 ел математика, физика, астрономия фәннәрен укыта. Ике класс чыгара. Ә 1982 елны Мөслим урта мәктәбенә математика укытырга килә. Ул вакытта мәктәп директоры Мөҗәһит Әхмәтҗанов була. 1987 нче елның гыйнварендә, яңа мәктәп ачылгач, шунда күчә. Һәр елны чыгарылыш классларда укыта. 50 медалист әзерли. 37 ел укытучы булып эшләү дәверендә Фиразия Рамазановна күп тапкырлар район мәгариф бүлеге "Мактау кәгазьләре" (2004, 2005, 2006, 2007, 2010, 2012), район хакимиятенең "Мактау кәгазе"нә (2003), Россиянең мәгариф һәм фән министрлыгының "Мактау кәгазьләре"нә (2006) лаек булган.